

Үткән атнада Казанда татар теле һәм әдәбиятыннан IX халыкара олимпиадасы vтте. Олимпиадада Россия Федерациясенен 23 тобәгеннән һәм 5 чит илдән  500 дән артык укучы балалар катнашты. Шулар арасында Мордовия Респуб-ликасынын оч районыннан биш укучы коч сынады.

Бу - Муртазина Самира (Ләмберә районы Татар Тавласы топ мәктәбе), Карабанов Радмир (Ләмберә районы Черемиш топ мәктәбе), Алькаева Римма (Ләмберә районы Пензятка урта мәктәбе), Халикова Хадиджа (Ромадан районы Белозерье урта мәктәбе), Жарков Шамиль (Кочкурово районы Сабаево урта мәктәбе).17нче апрельдән башланып киткән әлеге олимпиада vз эченә кызыклы чараларны туплады. Укучылар татар теле һәм әдәбиятыннан vзара белем осталыкларын сынаудан тыш, кvп кенә мәдәни чараларда да катнашты.  Кәрим Тинчурин театрында «Син минем бердәнберем», Галиасгар Камал театрында берничә спектакль, «Авторучка» фильмын карау һәм фильмда катнашкан артистлар белән очрашу, Татар дискотекасында катнашу,



Казан буйлап экскурсия – болар һәммәсе дә укучыларыбызнын рухи доньясын баетуга багышланган иде.
Мордовиябезнен Ләмберә районы Татар Тавласы топ мәктәбе укучысы Самира Муртазина олимпиада призеры исемен лаеклы яулады. Самира, татар теле белән татар әдәбияты предметлары буенча яхшы белемнәр кvрсәтvдән тыш, «Гаилә шәҗәрәсе»н

яклауда да беренчеләрдән булды.
«Мин туган телемне белvемә бик тә шат. Хис-кичерешләрем ташып тора. Йоклаганда уянам да, vземне һаман Казанда дип хис итәм; әкият илендә булып кайттык тосле тоела.



Олимпиадада кочле укучылар ярышты. Мин vзем Татар Тавласы топ мәктәбенен 8нче сыйныфында укыйм, ә олимпиадада 9нчы сыйныфлылар белән ярыштым. Призерлык яуладым.
Тагы бер бик тә кызыклы ярышта катнаштым, ул да булса «Минем шәжәрәм» проектын якладым. Гаиләм шәжәрәсе бик бай һәм кин. Аны бергәләп булдырдык: кем архивтан документлар, кем фотолар, кем генеалогик агач тозергә ярдәм итте. Бу проект - гаилә жимеше. Аны булдыруда әтием Ринат Кямиль улы Муртазин архивларда утырды, әнием Альфия Фатих кызы Муртазина (рәсемдә) эшне житәкләде, бабакаем Кямиль Сәяф улы Украинада яшәгән Ряйся апасыннан фотолар соратты. Әбием, Рәсимә Тагир кызы Азисова, әбиләребездән калган ядкәрләрне (тәсбих) саклаучы, бабайларымнын бабалары турында сойләvче булды.
Мин татар булуым белән горурланам, туган татар телемне белvемә шатмын. Бу ярыштан алган кичерешләремне, позитив эмоцияләремне озакка саклармын»,- дип хис-кичерешләре белән уртаклашты Самира Муртазина.
Калган укучыларыбыз да vзләрен сынатмады: олимпиада биремнәрен уныш-лы vтәделәр, туган татар телләрен яхшы белvләрен кvрсәттеләр. Без аларга килә-чәктә унышлар телибез!
Олимпиаданын ябылу тантанасы Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры Ильсур Гараевич Һадиуллин, кvренекле артистлар катнашында vтте.

**Фазия БОЯРОВА**